# КАРАР

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Звезда авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Чепкас-Ильмет авылында гражданнар җыены**

**24-нче ноябрь 2023 ел Чепкас-Ильмет авылы №1**

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының “Звезда авыл җирлеге " муниципаль берәмлегенең Чепкас-Ильмет торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 24 ноябре**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлеге Советының 11.10.2019 ел, № 53/1 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда, гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә, 2023 елның 24 ноябрендә төзелгән Хисап комиссиясенең, 2023 елның 24 ноябрендә узган халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә, тавыш бирү тәмамланган вакытта, җыенда катнашучы 175 кеше кертелгән, гражданнар җыенында катнашучыларның тавыш бирүдә катнашкан саны - **94**, бу исемлеккә кертелгән гражданнарның **53,90** % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан **94** кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде, бу гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучыларның **100%** ын тәшкил итә, «Каршы» позициясе өчен, җыенда катнашучы **0** кеше тавыш бирде, бу **0%** тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә карар иттеләр:

1. 2023 елның 24 ноябрендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Звезда авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Чепкас-Илмәт авылында уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләрен-дөрес дип танырга.
2. "Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Чепкас-Илмәт авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм

алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау" дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. 2024 елда Чүпрәле муниципаль районының Чепкас-Илмәт авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау.

4. Үзара салым акчаларын түләүдән азат итәргә:

1) 18 яшькә кадәрге дүрт яки аннан да күбрәк баласы булган гражданнарны;

2) инвалид балаларның (уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр) ата-аналарын, тулы дәүләт тәэмин ителешендә булган балаларны исәпкә алмаганда;

3) махсус хәрби операциядә катнашучыларны;

4) махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларын (хатыны (ире), балигъ булган балалар, ата-аналар һәм эшкә сәләтсез башка затлар белән бергә яшәүчеләр), шул исәптән махсус хәрби операция барышында хәбәрсез югалган һәлак булганнар да;

5) Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указына ярашлы рәвештә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар;

6) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренәхәрби хезмәткә мобилизация буенча чакырылган гражданнар гаиләләренең әгъзаларын (хатыны (ире), балигъ булган балалар, ата-аналар һәм эшкә сәләтсез башка затлар белән бергә яшәүчеләр).

5. Әлеге карарны Чепкас-Илмәт авылы, Клуб урамы, 4 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында, мәдәният йорты бинасында урнаштырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Звезда Башлыгы авыл җирлеге башлыгы,
рәислек итүче граңданнар җыенында: М.В.Денисова